КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 24 гыйнвар г.Казань № 36

Татарстан Республикасының Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы каршындагы нефть сәнәгате объектларында сәнәгать иминлеге һәм гадәттән тыш хәлләрне кисәтү өлкәсендә җитештерү эшчәнлеге һәм законнарны камилләштерү мәсьәләләре буенча техник совет турында

Татарстан Республикасының нефть чыгару компанияләре белән тикшерү-күзәтү органнары хезмәттәшлеген тәэмин итү һәм нефть сәнәгате объектларында сәнәгать иминлеге, янгын куркынычсызлыгы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә законнарны камилләштерү, әйләнә-тирә мохитне саклауны тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасының Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы каршындагы нефть сәнәгате объектларында сәнәгать иминлеге һәм гадәттән тыш хәлләрне кисәтү өлкәсендә җитештерү эшчәнлеге һәм законнарны камилләштерү мәсьәләләре буенча техник совет оештырырга.

2. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасының Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы каршындагы нефть сәнәгате объектларында сәнәгать иминлеге һәм гадәттән тыш хәлләрне кисәтү өлкәсендә җитештерү эшчәнлеге һәм законнарны камилләштерү мәсьәләләре буенча техник совет турындагы нигезләмәне расларга.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 24 гыйнвар, 36 нчы
карары белән расланды

Татарстан Республикасының Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы каршындагы нефть сәнәгате объектларында сәнәгать иминлеге һәм гадәттән тыш хәлләрне кисәтү өлкәсендә җитештерү эшчәнлеге һәм законнарны камилләштерү мәсьәләләре буенча техник совет турында

**НИГЕЗЛӘМӘ**

1. Бу Нигезләмә Татарстан Республикасының нефть чыгару компанияләре белән тикшерү-күзәтү органнары хезмәттәшлеген тәэмин итү һәм нефть сәнәгате объектларында сәнәгать иминлеге, янгын куркынычсызлыгы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә законнарны камилләштерү, әйләнә-тирә мохитне саклауны тәэмин итү максатларында эшләнде.

2. Татарстан Республикасының Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы каршындагы нефть сәнәгате объектларында сәнәгать иминлеге һәм гадәттән тыш хәлләрне кисәтү өлкәсендә җитештерү эшчәнлеге һәм законнарны камилләштерү мәсьәләләре буенча техник совет (алга таба – Техник совет) – ул даими эшләп торучы консультация киңәшмә орган булып тора һәм нефть сәнәгате объектларында сәнәгать иминлеге һәм гадәттән тыш хәлләрне кисәтү өлкәсендә артык булган административ киртәләрне бетерү буенча эш алып бару һәм сәнәгать иминлеге дәрәҗәсен арттыру максаты белән бу өлкәдә норматив хокукый җайга салуны камилләштерү буенча килештерелгән карарлар эшләү өчен оештырыла.

3. Техник совет үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, Татарстан Республикасы Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнарына, Россия Федерациясе Президенты һәм Татарстан Республикасы Президенты указларына һәм боерыкларына, Россия Федерациясе Хөкүмәте һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларына һәм боерыкларына, бу Нигезләмәгә таянып эш итә.

4. Техник советның төп бурычлары:

4.1. Нефть компанияләре эшчәнлеге барышында сәнәгать иминлеге һәм гадәттән тыш хәлләрне кисәтү өлкәсендә барлыкка килә торган проблемалы мәсьәләләрне карап тикшерү һәм аларны хәл итү буенча килештерелгән тәкъдимнамәләр әзерләү, шул исәптән:

4.1.1. Түбәндәгеләрне гамәлгә ашырганда җир асты байлыкларыннан файдаланучыларның чыгымнарын оптимальләштерү буенча закон чыгару башлангычын нигезләү турында тәкъдимнәр, материаллар әзерләү:

«Структурлаштырылган мониторинг системасы һәм биналарның, корылмаларның инженерлык системалары белән идарә итү» (алга таба – СМһИС) бүлеген эшләүне;

нефть чыгару объектларын хәбәр итүнең локаль системалары (алга таба – ХЛС) белән җиһазландыруны.

4.1.2. Куркыныч җитешетерү объектларында ХЛС һәм СМһИС оештыру өчен бертип схемалар, техник шартлар һәм башлангыч мәгълүматлар буенча тәкъдимнәр әзерләү.

4.1.3. Татарстан Республикасының нефть компанияләре өчен ХЛС һәм СМһИС оештыру проектларын төзү буенча бердәм тәкъдимнамәләр турында тәкъдимнәр әзерләү.

4.2. Артык булган административ киртәләрне бетерү өчен, ХЛС һәм СМһИС оештыруның норматив базасын, законнарны камилләштерү максатларында, нефть сәнәгате объектларында сәнәгать иминлеге һәм гадәттән тыш хәлләрне кисәтү өлкәсендә барлыкка килә торган проблемалы мәсьәләләргә, шулай ук әлеге өлкәләрдә норматив хокукый актларга үзгәрешләр кертү буенча башка мәсьәләләргә карата тәкъдимнәр һәм килештерелгән тәкъдимнамәләр әзерләү.

5. Техник совет рәисе:

Техник совет эшчәнлеге белән гомуми җитәкчелек итүне гамәлгә ашыра;

Техник совет компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына һәм Татарстан Республикасы Президенты Аппаратына карап тикшерүгә кертә.

6. Техник совет түбәндәгеләргә хокуклы:

Техник совет утырышында мәсьәләләрне карап тикшерү яки әзерләү барышында катнашуы һәм бәяләмә бирүе кирәк булган дәүләт хакимияте башкарма органнары, оешмалар вәкилләрен чакырырга;

Техник совет компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына һәм Татарстан Республикасы Президенты Аппаратына билгеләнгән тәртиптә кертергә.

7. Техник совет эшен оештыру:

7.1. Техник совет үз эшчәнлеген утырышлар үткәрү юлы белән гамәлгә ашыра.

7.2. Техник совет утырышлары кирәк булуга карап үткәрелә һәм, анда Техник совет әгъзаларының яртысыннан күбесе катнашса, тулы хокуклы дип санала.

7.3. Техник совет рәисе булмаганда, аның функциясе Техник совет рәисе урынбасарына йөкләнә.

7.4. Татарстан Республикасының Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы Техник совет утырышын үткәрү вакыты һәм урыны турында, шулай ук аның каравына кертелгән мәсьәләләр турында хәбәр итә.

7.5. Техник совет утырышлары беркетмә белән рәсмиләштерелә. Техник совет карарлары, әгәр аның өчен Техник советның утырышта катнашучы әгъзаларының яртысыннан күбесе тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала.

8. Техник совет эшчәнлеген оештыру-техник яктан тәэмин итүне Татарстан Республикасының Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы гамәлгә ашыра.

_______________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 24 гыйнвар, 36 нчы
карары белән расланды

Татарстан Республикасының Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы каршындагы нефть сәнәгате объектларында сәнәгать иминлеге һәм гадәттән тыш хәлләрне кисәтү өлкәсендә җитештерү эшчәнлеге һәм законнарны камилләштерү мәсьәләләре буенча техник совет

**СОСТАВЫ**

| | |
|---|---|
| Кәримов Альберт Әнвәр улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасының сәнәгать һәм сәүдә министры, Техник совет рәисе |
| Сабиров Ринат Касыйм улы | Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе, Техник совет рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Савельчев Алексей Петрович | Татарстан Республикасының сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасары, Техник совет рәисе урынбасары |

Техник совет әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Адиев Эльдар Рәшит улы | Татарстан Республикасы Премьер-министрының нефть-газ химиясе комплексы мәсьәләләре буенча ярдәмчесе |
| Беспалов Алексей Петрович | «В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлар җәмгыятенең Мәгълүмат технологияләре идарәсе башлыгы – баш инженер урынбасары (килешү буенча) |
| Вәлиев Фәнис Хаммат улы | «Нефтеконсорциум» ябык акционерлар җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Вәлиев Равил Фәрит улы | җаваплылыгы чикләнгән «Шешмаойл» идарә итүче компаниясе» җәмгыяте баш инженеры (килешү буенча) |
| Вышенский Олег Михайлович | «Нефтеконсорциум» ябык акционерлар җәмгыяте баш инженеры (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Ганиев Булат Гали улы | В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлар җәмгыятенең Нефть һәм газ ятмаларын эшкәртү буенча технологик идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Гусаров Владимир Петрович | В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлар җәмгыятенең хәрби-мобилизация эше, гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Запорожченко Алексей Анатольевич | җаваплылыгы чикләнгән «Сервис ННК» җәмгыяте генераль директоры урынбасары (килешү буенча) |
| Кәбиров Линар Әхмәтзаһит улы | «Консалтинг Үзәге» ябык акционерлар җәмгыяте директорының инвестиция проектлары буенча урынбасары (килешү буенча) |
| Карпов Родион Михайлович | Экология, технология һәм атом күзәтчелеге федераль хезмәтенең Идел буе идарәсенә караган Нефть чыгару сәнәгатендә күзәтчелек һәм тау күзәтчелеге буенча төбәкара бүлек башлыгы (килешү буенча) |
| Капралов Андрей Юрьевич | җаваплылыгы чикләнгән «Нефтегазпроект» җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Минаҗев Рәфикъ Рәис улы | В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлар җәмгыятенең сәнәгать, экология иминлеге һәм хезмәтне саклау идарәсе башлыгы урынбасары – сәнәгать иминлеге һәм хезмәтне саклау бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Ожередов Евгений Витальевич | җаваплылыгы чикләнгән «Проект МНК» җәмгыятенең баш инженеры (килешү буенча) |
| Петров Борис Германович | Экология, технология һәм атом күзәтчелеге федераль хезмәтенең Идел буе идарәсе җитәкчесе (килешү буенча) |
| Смыков Евгений Николаевич | В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлар җәмгыятенең Капиталь төзелеш идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Степущенко Олег Александрович | Татарстан Республикасының гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министры урынбасары |

| | |
|---|---|
| Суржко Николай Владимирович | Татарстан Республикасының гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министры урынбасары |
| Тишкин Василий Сергеевич | «Баш дәүләт экспертизасы идарәсе» федераль автоном учреждениесенең Казан филиалы башлыгы урынбасары (килешү буенча) |
| Фадеев Владимир Гелиевич | В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлар җәмгыятенең нефть чыгару процессларын җитештерү ягыннан тәэмин итү идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Хәлимов Рөстәм Хәмис улы | В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлар җәмгыяте генераль директорының нефть һәм газ эшкәртү һәм чыгару буенча урынбасары (килешү буенча). |